**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«04» 09 2026 ел Яр Чаллы шәһәре № 3029

2026 елга Тукай муниципаль районы территориясендә экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча комплекслы программаны раслау турында

Тукай муниципаль районы территориясенең тиешле санитар, эстетик торышын тәэмин итү һәм аны алга таба төзекләндерү максатында,

**КАРАР БИРӘ:**

1. «2026 елга Тукай муниципаль районы территориясендә экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча комплекслы программа»ны расларга.
2. Әлеге карарны муниципаль районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru).
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Н. Маняпов

# 2026 ЕЛГА ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ ЭКОЛОГИК КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫКНЫ ТӘЭМИН ИТҮ БУЕНЧА КОМПЛЕКСЛЫ ПРОГРАММА

Яр Чаллы шәһәре
2026 ел

# ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| **Программаның исеме** | Тукай муниципаль районы территориясендә экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча комплексы программа |
| **Программаны төп эшләүчеләр** | Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты |
| **Программаны башкаручылар** | - Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты;<br>- Авыл җирлекләре башкарма комитетлары;<br>- Авыл җирлекләре башлыклары |
| **Программаның максатлары һәм бурычлары** | Программаның төп максатлары:<br>- әйләнә тирәлеккә тискәре йогынтыны киметү, шулай ук аны саклау һәм яхшырту;<br>- Тукай муниципаль районында яшәүчеләр өчен уңайлы тормыш киңлеген булдыру.<br>Бу максатларга ирешү өчен түбәндәге төп бурычларны хәл итәргә кирәк:<br>- җир һәм су ресурсларын экологик һәм икътисадый тернәкләндерү |
| **Программаны тормышка ашыру вакыты** | 2026 |
| **Финанслау күләме** | Программаны финанслау күләме 16 559,76285 мең сум тәшкил итә |
| **Финанслау чыганаклары** | Федераль бюджет, ТР бюджеты, район бюджеты, авыл җирлекләре, инвесторлар бюджетлары средстволары (мең сум) |

| Финан-слау чыга-нак-лары | РФ бюд-жеты | ТР бюд-жеты | Район бюджеты/ авыл җирлекләре бюджетлары средство-лары | Пред-приятие сред-ство-лары | Инвес-тиция-ләр |
|---|---|---|---|---|---|
| 2026 | - | | 16 559,76285 | | |

Эшләрнең бәясе, барлыгы 16 559,76285 мең сум.

| | |
|---|---|
| **Программаны тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре** | Программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә экологик зыянны булдырмый калу 16 559,76285 мең сум күләмендә фаразлана.<br>Программа чараларын тулы күләмдә гамәлгә ашыру тиешле дәрәҗәдә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк:<br>- әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны киметү һәм экологик һәлакәтләрне булдырмау;<br>- район халкы өчен уңайлы тормыш киңлеген булдыру;<br>- халыкның тормыш сыйфатын һәм сәламәтлеген яхшырту өчен кирәкле шарт буларак, әйләнә-тирә мохитнең уңай торышын тәэмин итү;<br>- муниципаль берәмлек халкында экологик культура һәм әйләнә-тирә мохиткә сак караш формалаштыру; экологик зыянны булдырмау һәм халыкның экологик куркынычсызлыгын арттыру. |

## 1. ПРОГРАММАНЫҢ ТӨП МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

**Максатлар:**

- әйләнә тирәлеккә тискәре йогынтыны киметү, шулай ук аны саклау һәм яхшырту;
- Тукай муниципаль районы халкының тормыш сыйфатын һәм сәламәтлеген яхшырту өчен кирәкле шарт буларак, әйләнә-тирә мохитнең уңай торышын тәэмин итү.

**Бурычлар:**

- әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән рациональ файдалану өлкәсендә, тормыш эшчәнлеге өчен уңай шартлар тудыруга юнәлтелгән сәяси, икътисадый, технологик, хокукый, социаль, медицина, санитария-гигиена, эпидемиягә каршы чараларны исәпкә алып, дәүләт сәясәтен тормышка ашыру;
- җир, су, урман, минераль һәм башка ресурслардан файдалануның экологик нигезләнгән методларын кертеп, тотрыклы үсешкә юнәлтелгән табигатьтән комплекслы файдалануны гамәлгә кертү;
- хуҗалык эшчәнлегеннән тискәре экологик нәтиҗәләрне булдырмау, булачак экологик нәтиҗәләрне исәпкә алу;
- әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә идарә итү системасының функциональ нәтиҗәлелеген тәэмин итү;
- әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән рациональ файдалану өлкәсендә карарлар әзерләүдә, фикер алышуда, кабул итүдә һәм тормышка ашыруда катнашуны тәэмин итү.

## 2. Тукай муниципаль районында экологик куркынычсызлыкны, җир асты байлыкларыннан рациональ файдалануны һәм санитар-эпидемиологик иминлекне тәэмин итү буенча эшчәнлекне анализлау

Рөхсәтсез чүплекне ликвидацияләү проекты - законсыз чүплек нәтиҗәсендә барлыкка килгән әйләнә-тирә мохиткә зыянны бетерүгә юнәлтелгән чаралар комплексы.

Чүплекне ликвидацияләү (рекультивацияләү) ике этаптан тора.

Техник этап

Табигый ландшафтны торгызуга, техноген үзгәрешләрне бетерүгә юнәлтелгән. Кайбер чаралар:

- Чүплекне тигезләү, кирәк булганда - аның мәйданы арттыру, ләкин биеклегее киметү.

- Рельеф формалаштыру: чокырлар, иңкүлекләр һәм упкыннар күмәләр, полигон периметрын ныгыталар.

- Күрше җирләрне зарарламас өчен фильтрат һәм агынты суларны җыю өчен дренаж системалары урнаштыру.

- Дегазатор-системалар - полигоннан куркыныч чүплек газын (ул агулы, ут чыгу куркынычы бар һәм һаваны пычрата) чыгара торган системалар урнаштыру. Кайбер полигоннарда чүплек газын яндыралар, әмма заманча технологияләр аны алга таба куллану өчен эшкәртергә дә мөмкинлек бирә.

- Күп функцияле рекультивацион саклагыч экран булдыру.

Биологик этап

Туфрак катламын яхшыртуга юнәлтелгән. Кайбер чаралар:

- Полигон өслегендә уңдырышлы катлам әзерләү.

- Күпьеллык үләннәрне һәм үсемлекләрне әзерләү, аларны утырту һәм карау. Элеккеге чүплеккә утыртыла торган үсемлекләр, урнашуларына карап, төрле үзлекләргә ия булырга тиеш: салкыннарга, агулы газ тәэсиренә һәм корылыкка чыдам булырга тиеш.

- Туфракны органик һәм минераль ашламалар белән баету, аларның күләме туфрак компонентларының табигый балансын торгызу өчен җентекләп исәпләнә.

- Территорияне яшелләндерү: анда үләнчел үсемлекләр утырталар, бу табигый биологик төрлелек формалаштыру өчен нигез булып тора.

- Эрозиягә каршы чаралар үткәрү - алар эрозияне - уңдырышлы грунт кисәкчәләренең җилләтелүен һәм аның үзлекләренең начараюын булдырмауга юнәлтелгән.

Шунысы мөһим: биологик этап техник эшләр тәмамланганнан соң башлана, нәтиҗәдә ландшафт торгызылган һәм яхшыртылуга әзер. Биологик рекультивация сроклары грунтларның пычрану дәрәҗәсенә, ландшафт бозылу һәм биотөрлелек дәрәҗәсенә бәйле. Процессны тизләтү өчен, бозылган җирләрдә гидро чәчү - орлыкларны су эмульсиясе ярдәмендә утырту ысулы кулланылырга мөмкин.

Чүплекләрне бетерү максатлары:

Бу процесс калдыкларны саклау өчен файдаланылган җирләрне торгызу өчен кирәк. Рекультивация территорияне чүп-чардан чистартуны, туфрак һәм суның пычрануын бетерүне, шулай ук табигый үсемлекләрне торгызуны үз эченә ала. Чүплекләрдә куркыныч химик матдәләр җыела, алар грунтка һәм грунт суларына үтеп керә, атмосфераны пычрата, төрле авырулар үсешенә этәрә. Рекультивация бу куркынычларны бетерергә, туфракны табигый хәлгә кайтарырга мөмкинлек бирә. Элеккеге калдыклар саклау территориясендә үсемлекләрне һәм флораны торгызу биотөрлелекне сакларга һәм әйләнә-тирә мохиттә яшәү сыйфатын яхшыртырга ярдәм итә.

### 3. Төп юнәлешләр һәм чаралар.

Чүплекне бетерү - территорияне чүп-чардан чистарту һәм бозылган җирләрне торгызу процессы, мәсәлән, калдыкларны рөхсәтсез урнаштырганнан соң

Чүплекне бетерү - кеше эшчәнлеге нәтиҗәсендә уңдырышлылыгы сизелерлек кимегән җирләрне һәм су ресурсларын экологик һәм икътисадый торгызу буенча чаралар комплексы.

Чүплекне бетерү максатлары:
- әйләнә-тирә мохит шартларын яхшырту;
- җирләрнең һәм сулыкларның продуктлылыгын торгызу.

Калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру урыннары – калдыкларны урнаштыру өчен каралмаган территорияләр. Калдыкларны шәһәр һәм авыл җирлекләре янындагы территорияләрдә, урман-парк, курорт, дәвалау-савыктыру, ял итү зоналарында, хайваннар миграциясе юлларында, уылдык чәчү урыннары янында һәм әйләнә-тирә мохит, табигый экологик системалар һәм кеше сәламәтлеге өчен куркыныч тудырырга мөмкин булган башка урыннарда урнаштыру тыела (мәсәлән,

сусаклагычларның ярларында һәм вакытлыча су басу зоналарында, эчә торган су белән тәэмин итү чыганакларын санитар саклау территорияләрендә); шулай ук житештерү һәм куллану калдыкларын, шул исәптән радиоактив калдыкларны, өске һәм жир асты су объектларына, су жыю мәйданнарына, жир асты һәм туфракка ташлау тыела. Моннан тыш, торак пунктлар, су саклау зоналары чикләрендә, эчәргә яраклы һәм хужалык-көнкүреш максатларында кулланыла торган жир асты су объектларының су жыю мәйданнарында калдыкларны күмү тыела

Жир кишәрлеге милекчесе каты коммуналь калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру урыннарын бетерүне мөстәкыйль тәэмин итәргә яки каты коммуналь калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру өчен ачыкланган урынны бетерү буенча хезмәтләр күрсәтүгә региональ оператор белән килешү төзергә тиеш.

## 4. Программаны финанс белән тәэмин итү.

2026 елга программаны тормышка ашыру өчен ихтияж 16 559,76285 мең сум тәшкил итә.

## 5. Көтелгән соңгы нәтижәләр.

- әйләнә-тирәлеккә тискәре йогынтыны киметү һәм экологик һәлакәтләрне булдырмый калу;
- халыкның тормыш сыйфатын һәм сәламәтлеген яхшырту өчен кирәкле шарт буларак, әйләнә-тирә мохитнең уңай торышын тәэмин итү.
- экологик зыянны булдырмау һәм халыкның экологик куркынычсызлыгын арттыру;
- муниципаль берәмлек халкында экологик культура һәм әйләнә-тирәлеккә сак караш формалаштыру;
- район халкы өчен уңайлы тормыш кинлеген булдыру.

2026 елда Тукай муниципаль районы бюджеты акчалары хисабына финанслауга каралган табигатьне саклау чаралары исемлеге

мең сум

| № | Чара коды * | Табигатьне саклау чарасы исеме | Чараның тасвирламасы, егәрлеге | Гамәлгә ашыру срогы | Агымдагы бәяләрдәге бәясе | 2026 ел лимиты финанслау чыганаклары киселешендә | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | 2022 елның 2 августындагы 1370 номерлы карар, әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыдан керемнәр, штрафлар, дәгъвалар күләменнән | Файдалы казылмалар чыгаруга салым күләменнән | Барлыгы |
| 1. | 1.03 | "Тукай муниципаль районы, Кече Шилнә авыл жирлеге" Кече Шилнә торак пункты янында санкцияләнмәгән чүплек" "Әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектын рекультивацияләү объекты буенча проектка төзәтмәләр кертү | 16:39:102402:4424 кадастр номерлы жир кишәрлегендә "Тукай муниципаль районы, Кече Шилнә авыл жирлеге" Кече Шилнә торак пункты янында санкцияләнмәгән чүплек" "Әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектын рекультивацияләү объекты буенча проектка төзәтмәләр кертү, (ГРОНВОСка кертелгән) | 2026 | 1 941,00 | 1 941,00 | 0,00 | 1 941,00 |
| 2 | 4.11 | Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл жирлеге территориясендә калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру урыннарын ликвидацияләү | Координатлары 55.624179, 52.297300 булган жир кишәрлегендә калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру урыннарын ликвидацияләү | 2026 | 4 000,19 | 0,00 | 4 000,19 | 4 000,19 |
| 3 | 4.11 | Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл жирлеге территориясендә калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру урыннарын ликвидацияләү<br>(ТР Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының Кама буе территориаль идарәсеннән 29.05.2026 ел No 28-ТУК, 29-ТУК, 25-ТУК, 26-ТУК мәжбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтүләр) | Координатлары 55.617215 52.770625<br>55.615912 52.772395<br>55.614320, 52.770573<br>55.614004, 52.772365 булган жир кишәрлегендә калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру урыннарын ликвидацияләү | 2026 | 1 350,51 | 0,00 | 1 350,51 | 1 350,51 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4 | 4.11 | Тукай муниципаль районы Калмия авыл жирлеге территориясендә калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру урыннарын ликвидацияләү | Координатлары 55.825670, 52.756301 булган жир кишәрлегендә калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру урыннарын ликвидацияләү | 2026 | 3 470,30 | 0,00 | 3 470,30 | 3 470,30 |
| | | **Барлыгы 2026** | | | **10 762,00** | **1 941,00** | **8 821,00** | **10 762,00** |
| Табигатьне саклау чараларын 2025 елның файдаланылмаган калдыклары хисабына гамәлгә ашыру | | | | | | | | |
| 2 | 1.03 | "Тукай муниципаль районы, Кече Шилнә авыл жирлеге" Кече Шилнә торак пункты янында санкцияләнмәгән чүплек" "Әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектын рекультивацияләү объекты буенча проектка төзәтмәләр кертү | 16:39:102402:4424 кадастр номерлы жир кишәрлегендә "Тукай муниципаль районы, Кече Шилнә авыл жирлеге" Кече Шилнә торак пункты янында санкцияләнмәгән чүплек" "Әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектын рекультивацияләү объекты буенча проектка төзәтмәләр кертү, (ГРОНВОСка кертелгән) | 2026 | 1 127,75028 | 1 127,75028 | 0,00 | 1 127,75028 |
| 3 | 1.03 | Тукай муниципаль районы, Князево авыл жирлеге "Тукай муниципаль районы (Татарстан Республикасы) Сосновый Бор поселогында16:39:031502:18 кадастр номерлы жир кишәрлегендә санкцияләнмәгән чүплек" объекты буенча проект эшләү, дәүләт экология экспертизасын һәм объект буенча смета бәясен тикшерү буенча бәяләмә уздыру | Тукай муниципаль районы, Князево авыл жирлеге "Тукай муниципаль районы (Татарстан Республикасы) Сосновый Бор поселогында16:39:031502:18 кадастр номерлы жир кишәрлегендә санкцияләнмәгән чүплек" объекты буенча проект эшләү, дәүләт экология экспертизасын һәм объект буенча смета бәясен тикшерү буенча бәяләмә уздыру | 2026 | 4 233,65806 | 4 233,65806 | 0,00 | 4 233,65806 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4 | 7.01 | Тукай муниципаль районы. Мусабай-Завод авыл жирлеге территориясендә иске кыргый карьер калдыкларын, шул исәптән каты коммуналь калдыкларны урнаштыру объектларын рекультивацияләү (проект 2024 елда эшләнгән) | Мусабай-Завод авыл жирлеге территориясендә 16:39:081101:7 кадастр номерлы 10 000 кв. м мәйданлы иске кыргый карьерны рекультивацияләү, координаталары 55.455238 52.474885 | 2026 | 411,11084 | 0,00 | 411,11084 | 411,11084 |
| 5 | 4.11 | Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл жирлеге территориясендә калдыкларны рөхсәтсез ташлау урыннарын бетерү (Казан районара прокуратурасының 05.02.2025 ел Исорг-20000205-21-25/-20000205 номерлы күрсәтмәсе) | Координаталары 452987.895 2315163.349, 452985.222 2315165.582, 452980.198 2315165.545, 452965.407 2315170.395, 452963.520 2315177.631, 452947.825 2315174.349, 452919.935 2315170.395, 452903.055 2615160.330, 452903.705 2315149.478, 452988.263 2315158.294, 452987.895 2315163.349 булган жир кишәрлегендә калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру урыннарын бетерү | 2026 | 25,24367 | 0,00 | 25,24367 | 25,24367 |
| | | **Барлыгы 2025** | | | **5 797,76285** | **5 361,40834** | **436,35451** | **5 797,76285** |
| | | **Барлыгы** | x | x | x | **7 302,40834** | **9 257,35451** | **16 559,76285** |